**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы**

# КАРАР

**22.10.2025 ел** **№ 8**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2023 елның 22 ноябрендәге 112 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәрендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең үз көчен югалтуын тану турында**

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 11 сентябрендәге 1299/о номерлы боерыгы нигезендә, муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре Советы, КА**РАП ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2023 елның 22 ноябрендәге 112 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре үз көчен югалткан дип таныргa.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев